Кукмара муниципаль районы
Туембаш авыл җирлеге башлыгы
карары

29.12.2025 №8

**Татарстан Республикасы Кукмара районы Туембаш авыл җирлеген 2035 елга кадәр чорга су белән тәэмин итү схемасын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу схемалары турында» 2013 елның 5 сентябрендәге 782 номерлы карары нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Кукмара районы Туембаш авыл җирлеген 2035 елга кадәр чорга су белән тәэмин итүнең кушымта итеп бирелгән схемасын расларга.

2. Әлеге карарны Туембаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» челтәрендә Кукмара районының рәсми сайтына урнаштырырга.

Туембаш авыл җирлеге башлыгы И.Ф. Гарипов .

ОГРН 1021607753331
ИНН 1623003900

Туембаш авыл җирлеге башлыгының
2025 елның 29 декабрендәге 8 номерлы
карары белән РАСЛАНГАН

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**КУКМАРА РАЙОНЫ**

**ТУЕМБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕН**

**2035 ЕЛГА КАДӘР ЧОРГА**

**СУ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ**

**СХЕМАСЫ**

2025 ел

## I. Гомуми нигезләмәләр

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок Кучук авыл җирлеген су белән тәэмин итү схемасы – су белән тәэмин итү системасының нәтиҗәле һәм имин эшләвен, аны хокукый җайга салуны исәпкә алып үстерүне нигезләү буенча материаллар булган документ.

Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлеген су белән тәэмин итү схемасын эшләү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1. «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон;

2. РФ Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу схемалары турында» 2013 елның 5 сентябрендәге 782 номерлы карары.

Су белән тәэмин итү схемасы территориаль планлаштыру документлары һәм җирлекнең коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программалары нигезендә эшләнә.

Су белән тәэмин итү схемасы 10 елга эшләнгән.

## II. Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу схемасының төп максатлары һәм бурычлары

- техник мөмкинлеге булганда, мондый тоташтыруны башкарырга тиешле капиталь төзелеш объектын һәм оешманы су белән тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру мөмкинлеген билгеләргә;
- норматив таләпләр нигезендә су белән тәэмин итү системаларының ышанычлылыгын арттырырга;
- озак сроклы перспективада һәр кулланучыга исәпләгәндә су белән тәэмин итүгә чыгымнарны минимальләштерергә;
- Туембаш авыл җирлегендә яшәүчеләрне су белән тәэмин итү челтәренә тоташтыру һәм җирлектә яшәүчеләрне хуҗалык-эчү билгеләнешендәге су белән тәэмин итү зарур булганда тәэмин итәргә.

### 1 бүлек. Җирлек буенча су белән тәэмин итү турында белешмәләр

### 1. Татарстан Республикасы Кукмара районы Туембаш авыл җирлегенә кыскача характеристика

Туембаш авыл җирлеге чиге «Территорияләр чикләрен билгеләү һәм «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә кабул ителде (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән).

Туембаш авыл җирлеге составына әлеге закон нигезендә түбәндәгеләр керә: Туембаш авылы, Чуллы авылы.

Туембаш авыл җирлеге Татарстан Республикасы Кукмара районының төньяк-көнчыгышында, Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәреннән 15 км ераклыкта урнашкан. Туембаш авыл җирлеге Зур Кукмара, Зур Сәрдәк, Күкшел авыл җирлекләре һәм Киров өлкәсе белән чиктәш.

2025 елның 01 гыйнварына Туембаш авыл җирлегендә халык саны – 719 кеше.Административ үзәге – Туембаш авылы. Авыл җирлеге чикләрендәге территория

мәйданы – 2720 га. Барлык җирлекнең торак фонды 23,2 мең кв.м гомуми мәйданны тәшкил итә, шул исәптән Туембаш авылында – 15,5 мең $м^2$, Чуллы авылында - 7,7 мең $м^2$.

Рельефы – типик эрозияле. Территория эрозияләнә торган гидрографик челтәрле, хуҗалык чикләрендә күп санлы чокырлар һәм ерымнар урнашкан.

Хәзерге эрозиянең төп учаклары көтүлек һәм сирәгрәк сөрүлек биләгән чокыр һәм ерымнар буе битләүләрендә барлыкка килә. Эрозия агым белән юылу, ерганаклар, яр буе һәм сөзәк чокырлар рәвешендә барлыкка килә. Чокырларның һәм ерымнарның бу өлешендә икенчел эрозия ясалмалары – әлеге чокырлар һәм су ашаган урыннар бар.

Җирлек территориясендә хәзерге эрозиянең барлыкка килүе һәм үсеше урынның дулкынсыман рельефлы булуына, яссы һәм аерым-аерым тау битләренең шактый текә булуына, грунтның җиңел җимерелә торган булуына бәйле.

Территориядәге туфрак төрлелеге: кубесесенчә урман-дала туфрагы (231 га), соры урман туфрагы (1341 га) һәм көрән-соры туфрак (936 га). Чирәмле-карбонатлы туфрак шактый азрак мәйданны алып тора (35 га).

Климаты уртача-континенталь, кышы салкын, җәе җылы, эссе. Климатик район – 1В. Тышкы һаваның исәпләнгән температурасы – минус 32 С, ел фасыллары ачык чагыла. Норматив җил басымы – 30 кг/кв.м. Исәпләнгән кар йөкләнеше – 240 кг/кв.м. Туфрак туңуның норматив тирәнлеге – 1,7 м. Климат өчен ел фасылларының кучеш чорлары кискен алмашыну, озын салкын кыш һәм уртача җылы җәй хас. Чагыштырмача тигез, аз гына калкулыклы рельеф һәм тау киртәләренең булмавы Атлантик океаннан һава агымнарының иркле үтеп керүенә ярдәм итә, бу исә кышның кырыслыгын киметә. Язын көньяк һәм төньяк юнәлешләрдәге җилләрнең киңлекара алмашынуы көчәя. Бу язын тотрыксыз температура режимын тудыра. Май-июнь айларында салкыннарның кабат кайтуы һәм хәтта кар явуы күзәтелә.

Җирлекнең төп табигый ресурслары булып хуҗалык-эчү билгеләнешендәге җир асты геотермаль сулары тора.

Туембаш авыл җирлеге территориясендә 2 скважина урнашкан. Су белән тәэмин итү хезмәтләрен Туембаш авыл җирлеге хакимияте күрсәтә, ул түбәндәге эшләрне башкара:

- хуҗалык-эчү һәм авыл хуҗалыгын су белән тәэмин итү өчен җир асты төче суларын чыгару;
- кулланучыларны су белән тәэмин итү системасына тоташтыру;
- сүүткәргеч челтәрләренә хезмәт күрсәтү;
- исәпләү приборларын (су үлчәү приборларын) урнаштыру, аларны пломбалау;
- су белән тәэмин итү линияләрен, су җыю манараларын демонтажлау һәм монтажлау.

Предприятиеләрнең хезмәтләрдән файдаланучылар белән үзара мөнәсәбәтләре килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфаты гамәлдәге законнарда билгеләнгән таләпләргә туры килә. Су белән тәэмин итү системаларын техник эксплуатацияләүне оештыру аларның тиешенчә файдаланылуын һәм сакланышын тәэмин итә. Предприятиеләр су белән тәэмин итү буенча хезмәтләрне мөстәкыйль рәвештә күрсәтәләр.

## 2. Проект карарлары.

Туембаш авыл җирлеген су белән тәэмин итүнең проект чишелешләре, челтәр һәм корылмаларның факттагы торышын исәпкә алып, эшләнә торган Генераль план нигезендә ихтыяҗның артуы нигезендә гамәлдәге барлыкка килгән су белән тәэмин итү системасы нигезендә нигезләнә.

Җирлекне су белән тәэмин итү системасы үзәкләштерелгән, хуҗалык-эчү системасы – билгеләнеше буенча, тупик системасы – конструкциясе буенча.

Халыкка эчәрлек сыйфатлы су бирү хуҗалык-эчү ихтыяҗларына һәм су сибүгә, җитештерү предприятиеләренең технологик ихтыяҗларына, янгын сүндерүгә каралган.

### 3. Су белән тәэмин итү чыганаклары, су белән тәэмин итү схемасы.

### Туембаш авыл җирлеген үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларының техник-икътисадый торышы

Су белән тәэмин итү түбәндәге торак пунктларда гамәлгә ашырыла: Туембаш авылы, Чуллы авылы.

Җирлек халкын һәм хуҗалыкларын су белән тәэмин итүнең төп чыганагы булып 2 чишмә һәм 2 артезиан скважинасының җир асты сулары тора.

Туембаш авыл җирлеге администрациясе түбәндәге торак пунктларны су белән тәэмин итә: Туембаш авылы, Чуллы авылы. Туембаш торак пунктын су белән тәэмин итү Туембаш торак пунктының көньяк читендәге Клуб урамында урнашкан су алу скважинасыннан башкарыла.

Скважина2-12 елда 60 м тирәнлектә бораулангап һәм эш диаметры 168 мм булган ике колонналы конструкциягә ия. Торба артындагы аралык 10 метрдан 131 метрга кадәр тирәнлек интервалында вак таш белән күмелгән. Скважинаның конструкциясе продуктив сулы горизонтны өслектән пычранудан ышанычлы изоляциялəүне тəэмин итми.

Скважинада югары Казан карбонат-терриген һәм түбән Казан терриген-карбонат комплекслары бергә файдаланыла.

Скважина тамагы павильон белән ябылган. Санитар сак зонасының беренче поясы коймасы бар. Скважинадагы су өсте тигезлегенең торышын һәм алына торган суның күләмен күзәтү алып барыла. Су чыгымын исәпкә алу өчен, су үлчәү узелларының счетчиклары бар.

Су хуҗалык-эчү ихтыяҗларына Туембаш торак пунктында кулланыла. Суга ихтыяҗ елына 10000 куб м (тәүлегенә 27,4 куб м) тәшкил итә.

Суүткәргеч корылмалары: 2 су башнясы Рожновский конструкциясендәге бак сыйдырышлылыгы V=35 куб м, стволның биеклеге бак төбенә кадәр Н=18 м. Скважинадан чыгу юлында диаметры 100 мм булган бер, 80 мм булган ике корыч эшермә бик урнаштырылган. Насос белән күтәрелә торган су скважинадан су башнясына бирелә, аннан бикләр аша суүткәргеч челтәренә керә, артык су су башнясында кала, ул насос сүнгән вакытта тотыла. Электр суырткыч насосны эшләтеп җибәрү һәм туктату су җыю башнясы багындагы су дәрәҗәсенә бәйле рәвештә автомат рәвештә башкарыла.

Туембаш авылының торак фондының суүткәргеч челтәре ГОСТ 18599-100* полиэтилен суүткәргеч торбалар системасыннан гыйбарәт. Суүткәргеч челтәренең гомуми озынлыгы 8300 м. Суүткәргеч челтәре йорт яны кишәрлекләре (бакчалар) аша үткәрелгән, 17 янгын гидранты урнаштырылган. Диаметры 200 мм булган суүткәргеч коелар тимер-бетон боҗрадан, тимер торбалардан ясалган.

Җир асты суларының сыйфаты өйрәнелгән химик состав күрсәткечләре һәм микробиологик күрсәткечләр буенча СанПиН 2.1.4.1074-01 «Эчә торган су» норматив таләпләренә туры килә.

Чуллы авылын су белән тәэмин итү Чуллы авылында Хаҗи Закиров урамында урнашкан су алу скважинасыннан башкарыла.

70 м тирәнлектәге скважина 2013 елда бораулангап, аның эш диаметры 168 мм булган бер колонналы конструкциясе бар. Торба артындагы аралык 18 метрдан 80 метрга кадәр интервалда вак таш белән күмелгән. Эшләү өлеше 60-75 м тирәнлек интервалында урнашкан.

Скважинаның конструкциясе продуктив сулы горизонтны өслектән пычранудан ышанычлы изоляциялəүне тәэмин итми.

Скважина елына 365 көн түбән Казан терриген-карбонат су йөртү комплексы файдаланыла

Су хуҗалык-эчү ихтыяҗлары өчен Чуллы торак пунктында кулланыла. Суга ихтыяҗ елына 8670 куб м (тәүлегенә 23,8 куб м) тәшкил итә.

Скважина тамагы павильон белән ябылган, павильон идәне бетонланган. Санитар сак зонасының беренче поясы коймасы бар. Скважинадагы су өсте тигезлегенең торышын һәм алына торган суның күләмен күзәтү алып барылмый.

Су суырту корылмалары, су манарасы Рожновский конструкциясендәге бак сыйдырышлылыгы V=15 куб м, стволның биеклеге бак төбенә кадәр H=10 м. Скважинадан чыгу юлында диаметры 100 мм булган бер, 80 мм булган ике корыч эшермә бик урнаштырылган. Насос белән күтәрелә торган су скважинадан су башнясына бирелә, аннан бикләр аша сүүткәргеч челтәренә керә, артык су су башнясында кала, ул насос сүнгән вакытта тотыла. Электр суырткыч насосны эшләтеп җибәрү һәм туктату су җыю башнясы багындагы су дәрәҗәсенә бәйле рәвештә автомат рәвештә башкарыла.

Чуллы авылының торак фондының сүүткәргеч челтәре ГОСТ 18599-83* полиэтилен сүүткәргеч торбалар системасыннан гыйбарәт. Сүүткәргеч челтәренең гомуми озынлыгы 3500 м. 9 су алу колонкасы урнаштырылган. Диаметры 1200 мм булган сүүткәргеч коелар тимер-бетон боҗрадан ясалган. Төзелгән датасы – 2013 ел.

Җир асты суларының сыйфаты химик составының өйрәнелгән күрсәткечләре һәм микробиологик күрсәткечләре буенча «Эчә торган су» СанПиН 2.1.4.1074-01 нормативы таләпләренә туры килә.

## 4. Җирлек буенча үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларының төп проблемалары:

1. Кулланучыларга су бирә торган сүүткәргечләрдә кирәкле чистарту корылмалары (зарарсызландыру җайланмалары) комплексы булмау.
2. Су чистартуның заманча технологияләре булмау.
3. Су чыгымнарын исәпкә алу өчен, эчке сүүткәргеч белән җиһазландырылган һәр бинада су үлчәү узеллары урнаштыру тәкъдим ителә.

Сүүткәргеч корылмаларында СНиП 2.04.02-84 һәм СанПиН 2.1.4.1110-02 нигезендә санитар саклау зонасы булырга тиеш.

## 5. Су белән тәэмин итү чыганакларын санитар саклау зоналары.

Санитар саклау зоналары барлык су чыганакларында һәм хуҗалык-эчү билгеләнешендәге сүүткәргечләрдә аларның санитар-эпидемиологик ышанычлылыгын тәэмин итү максатларында каралырга тиеш.

Су белән тәэмин итү чыганакларын пычранудан саклау максатларында «Су белән тәэмин итү чыганакларын һәм эчәргә яраклы сүүткәргечләрне санитар саклау зоналары» СанПиН 2.1.4.1110-02 таләпләре нигезендә өч поястан торган санитар саклау зоналары оештыру күздә тотыла:

Санитар саклау зоналарының беренче поясына скважина тирәсендәге 30 – 50 м радиустагы территория кертелә. Беренче пояс территориясе киртәләнә һәм төзекләндерелә, баш корылмаларда эшләмәүче затларга керү тыела.

Икенче һәм өченче чикләү режимнарының санитария саклау зоналары поясы. Икенче һәм өченче пояслар зонасына махсус эзләнүләр нигезендә «Су белән тәэмин итү чыганакларын һәм эчәргә яраклы сүүткәргечләрне санитар саклау зоналары» СанПиН 2.1.4.1110-02 таләпләре нигезендә су алуны ышанычлы санитар яклауны тәэмин итә торган территорияләр кертелә. Икенче һәм өченче пояслар территориясендә чикләнгән санитария режимы урнаштырыла.

**6. Су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системаларын үстерү юнәлешләре;**

Үсешнең төп юнәлешләре:

1. Су белән тәэмин итүнең ышанычлылыгын һәм өзлексезлеген арттыру.

2. Җитештерүчән булмаган су югалтуларның кимүе.

3. Объектларның санитар-эпидемиологик таләпләргә туры килүен тәэмин итү.

4. Перспектив ихтыяҗны тәэмин итү өчен, челтәрләрне үстерү.
Төп бурычлар: тузган суүткәргеч челтәрләрен Ø110÷63 мм, ПЭ100) этаплап реконструкцияләү һәм алыштыру, җиһазларны алыштырып, скважиналарны капиталь ремонтлау, санитар саклау зоналарын төзү һәм суны исәпкә алу узеллары белән җиһазлау.

**7. Кайнар, эчәргә яраклы, техник су белән тәэмин итү һәм куллану балансы;**

Җирлекне су белән тәэмин итү системасы халыкны хуҗалык-эчү ихтыяҗлары өчен салкын су белән генә тәэмин итә. Кайнар су белән тәэмин итү йортларда индивидуаль рәвештә башкарыла, техник су белән тәэмин итү (су сибү, янгын сүндерү) шул ук системадан тәэмин ителә.

- **Су бирү (су белән тәэмин итү):** Су бирүнең гомуми тәүлеклек күләме халык саныннан (719 кеше) һәм су куллану нормативыннан чыгып бәяләнә. Гамәлдәге скважиналарның агымдагы һәм перспективалы ихтыяҗларны каплау өчен суммар дебиты җитәрлек.

- **Куллану:** Суның төп күләме (якынча 95-98%) халык тарафыннан хуҗалык-эчү ихтыяҗларына тотыла. Аз гына күләме йорт яны кишәрлекләренә су сибү һәм янгын куркынычсызлыгын (башняларда янгынга каршы су запасы) тәэмин итү өчен кулланыла. Бирелә торган суның шактый өлеше (бәяләүләр буенча 30-40% ка кадәр) югары дәрәҗәдә тузганлык аркасында челтәрләрдә югала.

- **Баланс:** Киләчәктә, агып чыгуларны бетергәннән соң, су бирү күләме перспективалы үсешне һәм сәгатьлек тигезсезлек коэффициентын исәпкә алып, халыкның фактагы кулланы белән корреляцияләнәчәк.

**8. Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системалары объектларын төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләү буенча тәкъдимнәр;**

1. **Реконструкциләү һәм модернизацияләү:** Гамәлдәге артезиан скважиналарына капиталь ремонт (иске җиһазларны сүтү, суны кудыру, насосларны алмаштыру, оголовокларны ремонтлау).

2. **Яңа төзелеш:** Торак пунктларның бөтен территориясен колачлау челтәрен үстерү.

3. **Төзекләндерү:** Барлык скважиналарның санитар саклау проект зоналарын төзү, һәр скважинаны һәм эчке суүткәргечле һәр бинаны су үлчәү узеллары белән җиһазлау.

**9. Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системалары объектларын төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләү буенча Чараларның экологик аспектлар;**

Чараларга табигатьне саклау һәм мохитне яхшырту характеры хас:

1. Су югалтуларны киметү җир асты су ресурсларыннан нәтиҗәле файдалануга китерә.

2. Санитар саклау зонасын төзекләндерү һәм скважиналарны ремонтлау сулы горизонтларның потенциаль пычрануын булдырмый кала.

3. Заманча полиэтилен торбалар куллану системаның герметиклыгын арттыра, челтәрдәге суның пычрану һәм пычраткыч матдәләрнең грунтка үтеп керү куркынычын киметә.

4. Эшләр башкару чорында туфрак катламын саклау, эрозияне булдырмау һәм төзелеш чүп-чарын утильләштерү буенча чаралар күрергә кирәк.

**10. Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системалары объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә һәм модернизацияләүгә капитал салулар күләмнәрен бәяләү;**

Капитал салулар күләме эшләнгән проект-смета документлары нигезендә төгәлләштерелергә тиеш. Алдан бәяләү үз эченә түбәндәге чыгымнарны ала:

- 4 скважинага капиталь ремонт ясау.
- Берничә чакрымга сузылган суүткәргеч челтәрләрен реконструкцияләү һәм яңаны төзү.
- Су үлчәү узелларын төзү һәм санитар саклау зонасын төзекләндерү.
Финанслауның планлаштырыла торган төп чыганагы булып, «Чиста су» федераль һәм республика программалары акчалары тора.

**11. Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларын үстерү күрсәткечләренең планлы күрсәткечләре;**

Схеманы гамәлгә ашыру чорына (10 ел) планлы күрсәткечләр үз эченә түбәндәгеләрне ала:

1. Челтәрләрнең тузуын 30 % тан да артык булмаган дәрәҗәгә кадәр киметү.

2. Транспортировка вакытында су югалтуны 10-15% ка кадәр киметү.

3. Үзәкләштерелгән система гамәлдә булган зонада яшәүче 100 % халыкны сыйфатлы эчәр су белән тәэмин итү.

4. Барлык гамәлдәге чыганакларның санитар саклау зонасын төзекләндерү.

5. Суны исәпкә алу объектларын 100 % җиһазландыру.

6. Су белән тәэмин итү системасының ышанычлылыгын норматив күрсәткечләргә кадәр күтәрү.

**12. Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларының ачыкланган хуҗасыз объектлары исемлеге (алар ачыкланган очракта) һәм аларны эксплуатацияләүгә вәкаләтле оешмалар исемлеге.**

Туембаш авыл җирлеге территориясендә үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системасының хуҗасыз объектлары ачыкланмады. Барлык объектлар (2 скважина, 2 су башнясы, суүткәргеч челтәрләр) аларны эксплуатацияләүгә вәкаләтле Туембаш авыл җирлеге башкарма комитеты балансында тора.